**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.04.2026 г.Казань № 155

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны закончылык белән туры китерү максатында

**б о е р а м:**

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2023 елның 12 сентябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы комиссиясен төзү турында» 439 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2024 елның 21 июненнән 318 номерлы, 2024 елның 2 декабреннән 593 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы комиссиясе (алга таба – комиссия) турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Комиссия Министрлык боерыгы белән төзелә. Күрсәтелгән боерык белән комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия.

Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

7.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министр урынбасары (комиссия рәисе), Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (комиссия рәисе урынбасары), кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре секторы мөдире, кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча секторның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны кисәтү эшенә җаваплы вазыйфаи заты (комиссия секретаре), юридик һәм мобилизацион эш, шулай ук Министрлыкның министр тарафыннан билгеләнгән башка бүлекләреннән дәүләт хезмәткәрләре;»;

9 пунктта «Килешү мөрәҗәгать алган көннән алып 10 көн эчендә башкарыла.» сүзләрен төшереп калдырырга;

15 пунктның «а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәдә каралган дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыру хакында;»;

21 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәдә нигезендә дәүләт хезмәткәрләре тапшырган белешмәләрнең дөрес һәм тулы булуын билгеләргә;».

Министр В.А. Леонов